**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2020 елның 28 феврале** **№ 152**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең коррупциячел хокук бозуларны кылган өчен җаваплылыгы турында» 2012 елның 13 декабрендәге 63 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә" Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге Советы **КАРАР чыгарды:**

1.«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең

коррупциячел хокук бозуларны кылган өчен җаваплылыгы турында» 2012 елның 13 декабрендәге 63 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турындагы Нигезләмәгә 1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«1.3. Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм төшерү тәртибе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.»

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

ТР, Кама Тамагы районы, Кама Тамагы ш. т. б., Совет ур., ҖҮИ бинасы);

ТР, Кама Тамагы районы, Кама Тамагы штп, К.Маркс ур.105 йорт,(китапханә бинасы) Шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

«Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе- В.П. Сороковнин